**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ ИВАШКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

ул.Центральная, д.39, с.Ивашкино, 423113

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**ИВАШКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Үзек урамы, 39 йорт, Ивашкино авылы, 423113

тел./факс (84396) 3-82-19 email: Iva.Cmn2@tatar.ru

15 декабрь 2025 ел № 14

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районының**
**Ивашкино авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Ивашкино авыл җирлеге Башкарма комитетының 2026 елга җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә бюджет ассигнованиеләре бүлеп бирү турындагы мөрәҗәгатен карау хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы, «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 24.5 статьясына һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 77 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 5 октябрендәге 288-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Башкарма комитетның 2025 елның 06 ноябрендәге № 137 карарын карап, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Ивашкино авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2026 елга Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Ивашкино авыл җирлеге бюджетына бюджет ассигнованиеләренең җитәрлек булмавын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Ивашкино авыл җирлеге башкарма комитеты мөрәҗәгатендә күрсәтелгән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә аерым вәкаләтләрне финанслаудан кушымта нигезендә баш тартырга.

Ивашкино авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе Ф.П. Андреев

Советның 2025 елның 15 декабрендәге
14 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Башкарма комитет өчен 2026 елда бюджет ассигнованиеләрен бүлеп бирү өчен җирле әһәмияттәге мәсьәләләр исемлеге**

| № п\п | Бюджет ассигнованиеләре белән ныгыту өчен җирле әһәмияттәге мәсьәләләрнең аталышы | БАРЛЫГЫ мең сумнарда |
|---|---|---|
| 1 | Гидротехник корылманы декларация алды тикшерүе | 1000 |
| 2 | Эчә торган суның сыйфатын СанПинның билгеләнгән таләпләренә туры китерү | 2 100 |
| 3 | Су белән тәэмин итүгә лицензия алу өчен документлар әзерләү | 270 |
| 4 | Җир асты чыганакларын санитар саклау зоналары проектын эшләү | 370 |
| 5 | Шәһәр төзелеше планын әзерләү | 1 100 |
| 6 | Янгын гидрантларын ремонтлау һәм алыштыру | 380 |
| 7 | Дератизация чараларын үткәрүне тәэмин итү | 85 |
| 8 | Кышкы вакытта җирле әһәмияттәге юлларны норматив хәлдә тоту өчен махсус реагентлар сатып алу | 180 |
| 9 | Әккәрәй һәм Ивашкино авылларында рөхсәтсез чүплекләрне рекультивацияләү | 300 |
| 10 | Янгын сүндергечләр сатып алу, тутыру | 110 |
| 11 | Әккәрәй һәм Ивашкино авыллары мәдәният йортларында янгынга каршы чаралар (түбә һәм сәхнә тартмасы пропиткасы) | 120 |
| 12 | Аркалы металлодетекторлар сатып алу | 260 |
| 13 | Әккәрәй һәм Ивашкино авылларында террорчылыктан саклануны куркынычсызлык паспортлары нигезендә китерү ( тавыш белән ашыгыч хәбәр итүнең автоном системасын урнаштыру) | 60 |
| 14 | Әккәрәй һәм Ивашкино авыллары мәдәният йортларында видеокүзәтү урнаштыру (8 камера) | 160 |
| 15 | Гидротехник корылмаларны карап тоту | 600 |
| 16 | Юл билгеләрен урнаштыру | 25 |
| 17 | Янгынга каршы минераллаштырылган полосалар булдыру | 30 |
| 18 | Гидрант күрсәткечләрен урнаштыру | 30 |
| 19 | Эшләрнең башка төрләре | 350 |
| | **БАРЛЫГЫ:** | 7530 |